# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20.11.2020 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 20 ноябрендә 10:00 сәг һәм 2020 елның 20 ноябрендә 13:00 сәг уздырылган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Кадрәк авылында лампаларга, дроссельләргә, фонарьларга хезмәт күрсәтү, ремонт ясау һәм алыштыру һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

2. Кадрәк авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

3. Кадрәк авылының Заречная һәм Ленин урамындагы күперләрне ремонтлау (башкарылган эш өчен материалларны төзү һәм түләү);

4. Кадрәк авылының Ленин, Сосновая, Полевая, Заречная, Яшьләр урамнары юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю;

5. Кадрәк авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасының штаттан тыш йөртүчесенә хезмәт хакын түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, автоном электр белән тәэмин итү чыганагын сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 242 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 191 кеше, бу 78,9 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 191 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Кадрәк авылында лампаларга, дроссельләргә, фонарьларга хезмәт күрсәтү, ремонт ясау һәм алыштыру һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

2. Кадрәк авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

3. Кадрәк авылының Заречная һәм Ленин урамындагы күперләрне ремонтлау (башкарылган эш өчен материалларны төзү һәм түләү);

4. Кадрәк авылының Ленин, Сосновая, Полевая, Заречная, Яшьләр урамнары юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю;

5. Кадрәк авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасының штаттан тыш йөртүчесенә хезмәт хакын түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, автоном электр белән тәэмин итү чыганагын сатып алу).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы
А.А.Михайлов